ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 8 мае** **г.Чистополь** **№ 227**

“Вазыйфаи затларга административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзү вәкаләтләрен бирү хакында”гы
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Башкарма комитетының
2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

“Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”гы 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. “Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында”гы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карарына (2020 елның 17 февралендәге 78 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексы белән каралган административ хокук бозулар составының исемлеген түбәндәге пункт өстәргә:

“2.17 статьясы - Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлтелгән.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат сайтында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы П.Б. Емельянов